КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 июль г.Казань № 795

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт торак күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2018 ел, 9 апрель, 218 нче; 2018 ел, 24 август, 706 нчы; 2018 ел, 4 октябрь, 904 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1041 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 31 нче; 2019 ел, 21 июнь, 506 нчы; 2019 ел, 12 июль, 569 нчы; 2020 ел, 12 март, 185 нче; 2020 ел, 18 апрель, 305 нче; 2020 ел, 28 август, 750 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 824 нче; 2022 ел, 13 август, 809 нчы; 2023 ел, 4 февраль, 104 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.12 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.6 пунктта:

беренче абзацта «энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнарда» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «м» пунктчасын өстәргә:

«м) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә карата таләпләрнең, шулай ук күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәт дип каралган вентиляция һәм төтен каналларын карап тотуга карата таләпләрнең.»;

5.1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның 1 пунктындагы унынчы – унөченче абзацлары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин